РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» апрель, 2019 Олы Кайбыч авылы № 162

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында мемориаль такталар урнаштыру тәртибе Нигезләмәсен раслау турында

Кайбыч муниципаль районы, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе тарихындагы күренекле вакыйгаларны, үз эшчәнлекләре өлкәсендә файда китергән шәхесләрне тарихка кертеп калдыру өчен Мемориаль такталар проектлау, эшләү һәм урнаштыруны тәртипкә салу максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002елның 1 апрелендәге 163 номерлы «Татарстан Республикасында мемориаль такталар урнаштыру тәртибе Нигезләмәсен раслау турында» карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында мемориаль такталар урнаштыру тәртибе Нигезләмәсен расларга (Кушымта №1);
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына мемориаль такталар буенча Комиссия һәм аның составын эшләргә һәм расларга.
3. Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында мемориаль такталар урнаштыру тәртибе Нигезләмәсенә таянып эшләргә тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советының социаль –мәдәни мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин